ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан ш.

13.11.2023 № 239

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2023 елның 23 августындагы 183 номерлы боерыгы белән расланган 2023 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIV республика конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2023 елның 23 августындагы 183 номерлы боерыгы белән расланган 2023 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIV республика конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәреш кертеп, 5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.12. Конкурс нәтиҗәләре Дәүләт комитеты тарафыннан (аерым сценарий нигезендә) 2023 елның 8 декабреннән дә соңга калмыйча Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыру тантанасында игълан ителә».

2. Туристлык индустриясен үстерү бүлегенә (А.Р.Камалиев) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү эшен оештырырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча рәис урынбасары А.В.Софьинны җаваплы итеп билгеләргә.

Рәис С.Е. Иванов